| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**13.12.2019** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2742** |

Зарарлы (пычраткыч)
матдәләрнең рөхсәт ителгән
концентрацияләре нормалары
буенча

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәтнең (Росприроднадзор) Татарстан Республикасы буенча Идарәсенең 2018 елның 05 октябрендәге СВ 32.12.18.59 номерлы әйләнә-тирә мохиткә (су объектларына) зарарлы(пычраткыч) матдәләр агызуга рөхсәт язуы (лицензиясе) нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре предприятиеләреннән «ЗВКС» акционерлык җәмгыятенең үзәкләштерелгән суны чыгару системасына һәм чистарту корылмаларына килә торган агынты сулардагы зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең рөхсәт ителгән концентрацияләре (ДК) нормаларын расларга. (кушымта). Күрсәтелгән нормалар күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы оешмаларга (әлеге абонентлардан биологик чистарту корылмаларына керә торган агынтыларның (стокларның) рөхсәт ителгән иң чик концентрациясе нормалаштырылмый) кагылмый.
2. Әлеге карарның гамәлдә булу срогын 2020 елның 31 декабренә кадәр билгеләргә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зарарлы (пычраткыч) матдәләрнең рөхсәт ителә торган концентрацияләре нормалары буенча» 2018 елның 20 декабрендәге 2683 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигы Д.С. Анисимовка әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), «Зеленый Дол» һәм «Яшел Үзән» басмаларында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин